ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

07 . 06 2021 г. № 579

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә караган гомуми белем бирү оешмаларына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга 6 яшь 6 айдан кечерәк яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны кабул итү тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясы, Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына карата санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.43648-20 санитар кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә караган гомуми белем бирү оешмаларына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга 6 яшь 6 айдан кечерәк яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны кабул итү тәртибен расларга (кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – район Мәгариф идарәсе җитәкчесе Р.М. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче — А.Г. Сәйфетдинов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 7 нче июнь
579 нчы номерлы карары белән расланган
кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә караган гомуми белем бирү оешмаларына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга 6 яшь 6 айдан кечерәк яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны кабул итү тәртибен раслау турында

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә караган гомуми белем бирү оешмаларына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга 6 яшь 6 айдан кечерәк яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны кабул итүнең әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) гамәлгә куючы функцияләрен башкаручы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (алга таба - Мәгариф идарәсе) Мәгариф идарәсенә караган гомуми белем бирү оешмаларына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга 6 яшь 6 айдан кечерәк яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны кабул итүгә рөхсәт бирү, шулай ук Мәгариф идарәсенең һәм аңа буйсынган мәгариф оешмаларының үзара хезмәттәшлеге тәртибен регламентлаштыра.

1.2. Әлеге Тәртип түбәндәге норматив документлар нигезендә эшләнгән:

- «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;

- «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон;

- Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына карата санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.43648-20 санитар кагыйдәләрен раслау турында» карары

- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары – башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 28 августындагы 442 номерлы боерыгы;

- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы (алга таба текст буенча – Кабул итү тәртибе).

1.3. Башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга 6 яшь 6 айдан кечерәк яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны белем бирү оешмасының беренче сыйныфына кабул итү Гамәлгә куючы рөхсәте белән гамәлгә ашырыла ала, аның функцияләре Мәгариф идарәсе башкара.

1.4. Уку елы башлануга яше 6 яшь 6 айга җитмәгән балаларны укыту, әлеге яшьтәге балалар өчен белем бирү процессын оештыруга һәм шартларына карата барлык гигиена таләпләрен үтәп, гомуми белем бирү оешмасында үткәрелә. Гомуми белем бирү оешмасы әлеге яшьтәге балалар өчен белем бирү процессын оештыруга һәм шартларына аерым гигиена таләпләрен үтәүне тәэмин итмәгән очракта, ата-аналар аерым шартлар булмаганда, балага медицина күрсәтмәләре булмаган очракта, балаларны укытуга язмача ризалык бирергә хокуклы.

2. Эшне оештыру

2.1. Агымдагы уку елы башына 6 яшь 6 айга җитмәгән, яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны белем бирү оешмасының 1 сыйныфына кабул итүгә рөхсәтне, шулай ук рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы хәбәрнамәне дә Мәгариф идарәсе 6 яшь 6 айдан кечерәк яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны 1 сыйныфка кабул итү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә (алга таба – Комиссия) бирә.

2.2. Комиссия Мәгариф идарәсе боерыгы белән төзелә. Комиссия составына Мәгариф идарәсе белгечләре, муниципаль белем бирү оешмалары вәкилләре кертелә.

2.3. Агымдагы уку елы башына 6 яшь 6 айга җитмәгән, яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны белем бирү оешмасының 1 сыйныфына кабул итүгә рөхсәт алу өчен ата-аналар (законлы вәкилләр) гомуми белем бирү оешмасына директор исеменә гариза бирә (1 нче кушымта). Ата-аналар (законлы вәкилләр) имзасы белән аларның шәхси мәгълүматларын һәм баланың шәхси мәгълүматларын Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә эшкәртүгә ризалык теркәлә (2 нче кушымта).

Беренче сыйныфка кабул итү өчен гаризалар кабул итү Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибенең 14,17 пунктлары нигезендә башкарыла.

2.4. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

- баланың ата-анасы (законлы вәкил) яки укырга керүченең шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

- баланың туу турында таныклыгы яки мөрәҗәгать итүченең туганлыгын раслаучы документ күчермәсе;

- опека һәм попечительлек билгеләүне раслаучы документ күчермәсе (кирәк булганда);

- теркәлгән территориядә яшәү урыны яки вакытлыча яшәү урыны буенча баланы яки укырга керүчене теркәү турындагы документның күчермәсе яки яшәү урыны буенча теркәлү өчен документлар кабул итү турында белешмә (беркетелгән территориядә яшәүче баланы яисә укырга керүчене кабул иткән очракта яки башлангыч гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча укуга өстенлекле кабул итү хокукы кулланылганда);

- баланың ата-анасы (законлы вәкиленең) эш урыныннан белешмә (чираттан тыш яки беренче чиратта кабул итү хокукы булганда);

- психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсенең күчермәсе (булганда).

2.5. Карар кабул итү өчен, документлар комплекты комиссиягә җибәрелә. Гаризаны карау һәм Комиссия тарафыннан карар кабул итү башлангыч гомуми, төп

гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибенең 17,31 пунктлары нигезендә башкарыла. Комиссия карары, Комиссия составының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы була. Карар гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны карау нәтиҗәләре буенча ачык тавыш бирү юлы белән комиссия утырышында катнашучы Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Кабул ителгән карар комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә. Комиссия эше, кирәк булган очракта, ата-аналар (законлы вәкилләр) катнашында бала белән индивидуаль рәвештә башкарыла.

2.6. Комиссиянең эш нәтиҗәсе булып, 1 нче сыйныфка баланы кабул итү турында рөхсәт бирү турында карар (утырыш беркетмәсеннән өземтә), яисә 1 нче сыйныфка баланы кабул итү турында рөхсәт бирүдән нигезләнгән баш тарту тора, ул Комиссия утырышы узган көнне рәсмиләштерелә һәм Мәгариф идарәсе җитәкчесенә имзага җибәрелә.

2.7. Мәгариф идарәсе карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә:

- гариза бирүчегә баланы 1 нче сыйныфка кабул итү турында рөхсәт җибәрә;

- гариза бирүчегә баланы 1 нче сыйныфка кабул итү турында рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә бирә (җибәрә).

2.8. 6 яшь 6 айдан кечерәк яки 8 яшьтән өлкәнрәк баланы 1 нче сыйныфка белем алырга кабул итүгә рөхсәт бирүдән баш тартуның сәбәпләре:

- әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын тапшыру;

- баланың сәламәтлеге буенча ярамаган медицина күрсәтмәләре булу;

- анда буш урыннар булмау сәбәпле, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә һәм 88 статьясында каралган очраклардан тыш.

2.9. Башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча 6 яшь 6 айдан кечерәк яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны укырга кабул итүгә рөхсәт алганнан соң, белем бирү оешмасы югарыда күрсәтелгән балаларны Россия Федерациясе законнары һәм гомуми белем бирү оешмасында кабул итү кагыйдәләре нигезендә беренче сыйныфка кабул итә.

## 3. яшьтән өлкәнрәк балаларны беренче сыйныфка кабул итү тәртибе

3.1. Ата-аналар (законлы вәкилләр) документларны үз вакытында тапшыру өчен җаваплы.

3.2. 8 яше тулган баланы беренче сыйныфына кабул иткәндә, ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасында аның мәктәпкә вакытында билгеләнмәвенең сәбәпләрен аңлату булырга тиеш.

3.3. Белем бирү оешмасы өч көн эчендә ата-аналар тарафыннан «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны бозулары турында балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиягә хәбәр итә.

3.4. Балаларны мәктәпкә кабул итү турында гаризалар бирү вакытын калдыру әти-әнигә (законлы вәкилләргә) балага белем бирүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

1 нче кушымта

ТР Түбән Кама муниципаль районының «__ урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ директоры_________________________________________

_______________________________________________
адресы буенча яшәүче_____________________________
_______________________________________________
Элемтә телефоны:
_____________________________________

ГАРИЗА

Сездән минем кызым (улым)
_________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «__ урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ ___ сыйныфына кабул итүегезне үтенәм.

Баланың туу датасы: _________________________________________________________
Баланың яшәү урыны адресы һәм (яки) вакытлыча яшәү урыны адресы:
_______________________________________________________________________________
Мәктәптә укыды, (балалар бакчасына йөрде):
_______________________________________________________________________________
Ата-аналары турында мәгълүмат:
Әтисе (Ф. И. А.)
_________________________________________________________________
Әнисе (Ф. И. А.)
_________________________________________________________________
Баланың ата-анасының (законлы вәкилләренең) яшәү урыны адресы һәм (яки) вакытлыча яшәү урыны адресы:
____________________________________________________________
Ата-ана (законлы вәкил) булганда, электрон почта адрес(лар)ы, телефон номер(лар)ы _______________________________________________________
_______________________________________________________________________________
Чираттан тыш, беренче чираттагы яки өстенлекле кабул итү хокукы булу
_______________________________________________________________________________
Адаптацияләнгән белем бирү программасы буенча һәм (яки) психологик - медик - педагогик комиссия бәяләмәсе нигезендә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны яки индивидуаль реабилитация программасы нигезендә, инвалидны (инвалид баланы) укыту һәм тәрбияләүне оештыру өчен махсус шартлар тудыруга баланың яки укырга керүченең ихтыяҗлары.
_______________________________________________________________________________

Адаптацияләнгән белем бирү программасы буенча баланы укытуга (адаптацияләнгән белем бирү программасы буенча баланы укыту кирәк булган очракта) ата-ананың (законлы вәкил(ләр)нең ризалыгы;

_______________________________________________________________________________

Унсигез яшькә җиткән кешенең адаптацияләнгән белем бирү программасы буенча (адаптацияләнгән белем бирү программасы буенча баланы укыту кирәк булган очракта) укуга ризалыгы;

_______________________________________________________________________________

Белем бирү теле (Россия Федерациясе халыклары телләреннән туган телдә яки чит телдә белем алган очракта);

_______________________________________________________________________________

Россия Федерациясе халыклары телләреннән туган тел (Россия Федерациясе халыклары телләреннән туган телне, шул исәптән рус телен туган тел буларак өйрәнү хокукын гамәлгә ашыру очрагында);

_______________________________________________________________________________

Россия Федерациясе республикасы дәүләт теле (Гомуми белем бирү оешмасы тарафыннан Россия Федерациясе республикасы дәүләт телен өйрәнү мөмкинлеге бирелгән очракта);

_______________________________________________________________________________

Мәктәп уставы белән таныштым________________________________________________

Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия белән таныштым______

_______________________________________________________________________________

Мәктәпнең дәүләт аккредитациясе турында таныклыклыгы белән таныштым______

_______________________________________________________________________________

Төп белем бирү программасы белән таныштым __________________________

Мәктәпнең уку планы белән таныштым_______________________________________

Түбән Кама муниципаль районының «__ урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУнә укучыларны кабул итү кагыйдәләре белән таныштым________

_______________________________________________________________________________

Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән таныштырылды ___________________

Мәктәп эшчәнлеген регламентлаучы башка документлар белән таныштым________

_______________________________________________________________________________

Мәктәп сайты адресы белән (https://edu.tatar.ru/nkamsk/sch__) таныштым ____________

Имза: __________________

Дата:_______________________

2 нче кушымта

ШӘХСИ МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ ЭШКӘРТҮГӘ РИЗАЛЫК

Минем шәхси мәгълүматларны һәм баламның шәхси мәгълүматларын гариза һәм кушымта итеп бирелә торган документларда күрсәтелгән күләмдә, аны мәктәптә укытуны һәм тәрбияләүне оештыру максатыннан, эшкәртүгә ризалык бирәм.

Ата-ананың Ф.И.А.______________________
Дата: ________________________________
Имза:____________________________

Гаризага кушымта итеп тапшырам:

- баланың ата-анасы (законлы вәкиле) яки укырга керүченең шәхесен та-ныклаучы документ күчермәсе;

- баланың туу турында таныклыгы яки мөрәҗәгать итүченең туганлыгын раслаучы документ күчермәсе;

- опека һәм попечительлек билгеләүне раслаучы документ күчермәсе (кирәк булганда);

- теркәлгән территориядә яшәү урыны яки вакытлыча яшәү урыны буенча ба-ланы яки укырга керүчене теркәү турындагы документның күчермәсе яки яшәү урыны буенча теркәлү өчен документлар кабул итү турында белешмә (беркетелгән территориядә яшәүче баланы яисә укырга керүчене кабул иткән очракта яки башлангыч гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча укуга өстенлек-ле кабул итү хокукы кулланылганда);

- баланың ата-анасы (законлы вәкиленең) эш урыныннан белешмә (чираттан тыш яки беренче чиратта кабул итү хокукы булганда);

- психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсенең күчермәсе (булганда).

Ата-ананың Ф.И.А.____________________
Дата: ________________________________
Имза:____________________________